ЯКШӘМБЕ
21
МАРТ
1943 ел.
№ 64 (6786)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

## Колхоз партоешмаларының мөһим бурычы

ВКП(б) Өлкә Комитетының IX пленумы язгы чәчүгә әзерләнү һәм аны ватан сугышы шартларына җавап бирерлек итеп үткәрү буенча колхоз партоешмаларына гаять җаваплы бурычлар йөкләде. Бу бурычны тирәнтен аңлап, колхозга большевистик җитәкчелек иткән урыннарда язгы чәчүгә әзерлек тә тулысы белән тәэмин ителә. Мисалга Дөбьяз районы, «Кызыл байрак» колхоз партоешмасын (секретаре иптәш Салихова) алырга була. Бирәдә колхозчылар арасында политик-масса эшләре, социалистик ярыш киң җәелдерелгән. Агитаторлар бригадаларда һәм звеноларда партия, хөкүмәт карарларын тирәнтен аңлаталар. Күргәзмә агитациядә яхшы оештырылган. Алдынгыларның эш тәҗрибәләре, чәчүгә әзерлек буенча эштәге кимчелекләр күрсәтелеп системалы рәвештә стена газеталары чыгарыла. Коммунистлар, комсомолецлар колхозның иң җаваплы участокларына беркетелгәннәр. Алар колхоз производствосында алдынгы сафта баралар. Чәчүгә әзерлекнең барышы турындагы мәсьәләләр партоешманың җыелышларында әледән-әле тикшерелә. Чыгарылган карарларның үтәлешенә нык контроль оештырылган. Большевистик җитәкчелек нәтиҗәсендә, бу колхоз язгы чәчүгә тулысы белән әзер. Чәчүлек орлыклары җитәрлек кадәре салынган, агротехника чаралары планы үтәлгән, машиналар яхшы итеп ремонтланганнар. Бу колхозның члennары чәчү орлыгы җитмәгән күрше колхозларга ярдәм тәртибендә үз запасларыннан 120 центнер бөртекле ашлык, 100 центнер бәрәңге биргәннәр инде. Бу патриотик хәрәкәт колхозда дәвам итә.

Язгы чәчүгә әзерлек эшенә конкрет җитәкчелек итүче партоешмаларны башка кайбер районнардан да күрсәтергә була.

Ләкин күп кенә колхоз партоешмалары ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы карарларын үтәү өчен хәзергә кадәр җитәрлек көрәшмиләр әле. Чәчүгә әзерлекне кичекмәстән тәэмин итү урынына карарлар чыгару, сөйләнү белән генә чикләнүче оешмалар рәтенә Биләр районы «Путь Ленина» колхозы партоешмасын кертергә мөмкин. Чәчүгә әзерлекне тулысынча, кичекмәстән төгәлләү өчен монда көрәш оештырылмаган. Коммунистлар, комсомолецлар колхоз производствосында авангардлык күрсәтмиләр. Нәтиҗәдә колхозда машиналарга шушы көнгә кадәр ремонт төгәлләнмәгән. Колхоз чәчүлек орлыклары белән тәэмин ителмәгән, колхозчылардан чәчү орлыгы җыйнау эше оештырылмаган. Агротехника чаралары планы үтәлмәгән, атларның торышы начар. Кыскасы, бу колхозда язгы чәчүгә әзерлек эше өзеклектә. Ә ВКП(б) ның район комитеты бу партоешмага кирәгенчә практик булышлык күрсәтми. Кызганычка каршы, мондый партоешмалар Кама тамагы, Куйбышев, Тәмте һәм башка кайбер районнарда да бар.

Чәчүгә чыгарга санаулы гына көннәр калып бара. Чәчүне үткәрү гаять җаваплы һәм хәлиткеч чор икәнен яхшы аңларга, чәчүгә әзерлекне тулысы белән тәэмин итәргә кирәк.

Һәрбер колхозны чәчү орлыгы белән тулысынча, кичекмәстән тәэмин итү, үз колхозларын чәчү орлыгы белән тәэмин итү буенча алдынгы колхозчылар тарафыннан күтәрелгән хәрәкәткә җитәкчелек итү, авыл хуҗалыгы машиналарын тулысынча ремонтлау, агротехника чаралары планын үтәү, кадрлар әзерләү планының тулысынча үтәлүен тәэмин итү—партоешмаларның һич кичектерелми торган мөһим бурычы.

Язгы чәчүгә әзерлек мәсьәләсе белән көн саен шөгыльләнергә, коммунистларны, комсомолецларны колхоз производствосының хәлиткеч участокларына беркетергә һәм колхозчылар арасында политик-масса эшләрен киң җәелдерергә кирәк. Партоешмалар үзләренең эшләрен шулай оештырырга тиешләр ки, һәрбер колхозчы һәм һәрбер колхозчы хатын-кыз 1943 нче елда хәрби уңыш яулап алу өчен көрәштә үзен тулы мобилизацион хәлдә итеп хис итсен. Колхоз партия оешмаларының сугышчан бурычы әнә шул.

# ССР СОЮЗЫ ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## Сәнгать һәм әдәбият өлкәсендә 1942 нче елда булган күренекле эшләр өчен Сталин исемендәге премияләр бирү турында

Сәнгать һәм әдәбият өлкәсендә күренекле эшләр өчен Сталин исемендәге премияләр бирү турында СССР Халык Комиссарлары Советының 1939 нчы ел, 20 нче декабрь карарын һәм бу премияләрне 1942 нче ел өчен бирү турында 1942 нче ел, 18 нче ноябрь карарын үтәү йөзеннән, СССР Халык Комиссарлары Советы карар бирә:

Түбәндәге өлкәләрдә 1942 нче елда булган күренекле эшләр өчен Сталин исемендәге премияләр бирергә:

### А. МУЗЫКА.

#### I. ЗУР МУЗЫКАЛЬ-СӘХНӘ ҺӘМ ВОКАЛЬ ӘСӘРЛӘР (ОПЕРА, БАЛЕТ, ОРАТОРИЯ, КАНТАТА)

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Мариан Викторович Ковальга (Ковалевка)—«Емельян Пугачев» операсы өчен.

2. Арам Ильич Хачатурянга —Әрмәнстан ССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе—«Гаянә» балеты музыкасы өчен.

#### II. ЗУР ИНСТРУМЕНТАЛЬ ӘСӘРЛӘР

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премия**

1. Виссарион Яковлевич Шевалинга, РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе—«Славян квартеты» өчен.

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Сергей Сергеевич Прокофьевка—«7 нче соната» өчен.

2. Мохтар Әшрәфигә, Үзбәкстан ССР ның халык артисты—«Героик симфония» өчен.

#### III. КЕЧЕ ФОРМА ӘСӘРЛӘРЕ

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Николай Павлович Иванов-Радкевичка—«Капитан Гастелло», «Халык өчен үч алучылар», «Туган Москва», «Җиңү маршы» дигән хәрби маршлар өчен.

2. Василий Павлович Соловьев-Седойга,—«Рейдтагы кич», «Уйна, минем баяным», «Үч алу җыры» дигән җырлар өчен.

#### IV. КОНЦЕРТ-БАШКАРУ ЭШЛӘРЕ

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Владимир Владимирович Софроницкийга— РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе, пианист.

2. Давид Федорович Ойстрахка, РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе, Москваның П. И. Чайковский исемендәге дәүләт консерваториясе профессоры, скрипач.

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Лев Николаевич Оборинга, Москваның П. И. Чайковский исемендәге дәүләт консерваториясе профессоры, пианист.

### Б. ХУДОЖНИКЛЫК СӘНГАТЕ

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Александр Михайлович Герасимовка, РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе—«Октябрь гимны» дигән картинасы өчен.

2. Василий Николаевич Яковлевка—«Советлар Союзы Герое Яковлевның портреты» һәм «Партизан портреты» картиналары өчен.

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Николай Николаевич Жуковка—Кызыл Армия турындагы рәсемнәр сериясе өчен һәм «Маркс һәм Энгельс» дигән альбом иллюстрацияләре өчен.

2. Дементий Алексеевич Шмариновка—«Онытмабыз, гафу итмәбез» дигән график әсәрләр сериясе өчен.

### В. СКУЛЬПТУРА

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Константин Михайлович Мерабишвиллига—Тбилиси шәһәрендә куелган Шота Руставели памятнигы өчен.

2. Матвей Генрихович Манизерга, РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе—«Зоя» Космодемьянская» дигән скульптур фигура өчен.

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премия**

1. Вера Игнатьевна Мухинага, РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе—Ватан сугышы геройларыннан полковник Юсупов һәм полковник Хижнякның скульптур портретлары өчен.

### Г. ТЕАТР-ДРАМА СӘНГАТЕ

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Рубен Николаевич Симоновка, РСФСР ның халык артисты,—Е. Вахтангов исемендәге дәүләт театрында куелган «Олеко Дундич» спектаклендә Олеко Дундич һәм «Сирано де Бержерак» спектаклендә Сирано де Бержерак рольләрен башкарган өчен.

2. Алексей Дмитриевич Поповка, РСФСР ның халык аристы,—Кызыл Армия Үзәк театрында «Бик күптәннән» исемле спектакльне куйган өчен.

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Мирза ага Алиевка, Азербайҗан ССР ның халык артисты —Азербайҗанның Газизбеков исемендәге драма театрында «Мәхәббәт» спектаклендә Мәшһиди Голәм Хөсәен ролен башкарган өчен.

### Д. ОПЕРА СӘНГАТЕ

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе Александр Шамилеевич Мелик-Пашаевка, Ростислав Владимирович Захаровка, Петр Владимирович Вильямска, РСФСР ның атказанган артисты Александр Иосифович Батуринга, РСФСР ның атказанган артисткасы Елена Дмитриевна Шпиллерга, — СССР ның Ленин орденлы Дәүләт Академия Зур театрында «Вильһельм Телль» спектакле өчен.

2. СССР ның халык артисты Арий Моисеевич Пазовскийга, РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе Леонид Васильевич Баратовка, РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе Федор Федорович Федоровскийга,—С. М. Киров исемендәге Ленин орденлы Ленинград опера һәм балет Академия театрында «Емельян Пугачев» спектаклен куйган өчен.

### Е. ХУДОЖЕСТВОЛЫ КИНЕМАТОГРАФИЯ

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Грузия ССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе Михаил Эдишерович Чиаурелига, СССР ның халык артисты Акакий Алексеевич Хоравага, Грузия ССР ның халык артисткасы Верико Ивлиевна Анджапаридзега, — «Георгий Саакадзе» кино-картинасы өчен.

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Сценарист Евгений Осипович Габриловичка, режиссер Юлий Яковлевич Райзманга, артистка Валентина Ивановна Караваевага, — «Машенька» кино-картинасы өчен.

2. РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе Иван Александрович Пырьевка, СССР ның атказанган артисты Василий Васильевич Ванинга, — «Райком секретаре» кино-картинасы өчен.

### Ж. ХРОНИКАЛЬ-ДОКУМЕНТАЛЬ КИНЕМАТОГРАФИЯ

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Режиссер Леонид Васильевич Варламовка, оператор Борис Васильевич Вакарга, оператор Абрам Наумович Казаковка, оператор Валентин Иванович Орлянкинга, оператор Авенир Петрович Софьинга, — «Сталинград» кино-картинасы өчен.

2. Режиссер Валерий Михайлович Соловьевка, оператор Ансельм Львович Богоровка, оператор Анатолий Иванович Погорелыйга, оператор Владимир Львович Страдинга, оператор Ефим Львович Учительгә, — «Ленинград көрәштә» кино-картинасы өчен.

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Режиссер Василий Николаевич Беляевка, оператор Федор Григорьевич Короткевичка, оператор Владислав Владиславович Микошага, оператор Дмитрий Георгиевич Рымашевка, — «Карадиңгезлеләр» кино-картинасы өчен.

2. Оператор Иван Иванович Беляковка, оператор Теодор Захарович Бунимовичка, оператор Иосиф Наумович Вейнеровичка, оператор Виктор Николаевич Доброницкийга, оператор Давид Михайлович Ибрагимовка—1942 нче елгы «Союзкиножурналлар»га документаль рәсемнәр алган өчен.

### З. ХУДОЖЕСТВОЛЫ ПРОЗА ӘСӘРЛӘРЕ

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Алексей Николаевич Толстойга, СССР фәннәр академиясенең действительный члены, «Хождение по мукам» исемле романы (трилогия) өчен.

2. Ванда Львовна Василевскаяга — «Радуга» исемле хикәясе өчен.

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Павел Петрович Бажовка — «Малахит шкатулка» исемле китабы өчен.

2. Леонид Сергеевич Соболевка — «Морская душа» исемле хикәяләр җыентыгы өчен.

### И. ШИГЫРЬ

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Максим Фадеевич Рыльскийга — «Слово про ридну матир», «Свитова зоря», «Свитла зброя» исемле оборона җырлары һәм «Мандривка в молодисть» поэмасы өчен.

2. Михаил Васильевич Исаковскийга — «Шел со службы пограничник», «Провожание», «И кто его знает», «Катюша» исемле киң таралган җырларның һәм башкаларның текстлары өчен.

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премия**

1. Маргарита Иосифовна Алигерга — «Зоя» поэмасы өчен.

### К. ДРАМАТУРГИЯ

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Александр Евдокимович Корнейчукка — «Фронт» пьесасы өчен.

2. Леонид Максимович Леоновка—«Нашествие» пьесасы өчен.

(Ахыры 2 нче биттә)

---

*)ИСКӘРМӘ: «Фән, уйлап табу, сәнгать һәм әдәбият өлкәсендә, 1942 нче елда булган күренекле эшләр өчен Сталин исемендәге премияләр турында» Халык Комиссариаты Советының 1942 нче ел, 18 нче ноябрь карарының бер өлешен үзгәртеп, СССР Халык Комиссариаты Советы үзенең бу карарында Сталин исемендәге премияләрне бирү буенча музыка өлкәсендә түбәндәгеләрне күздә тотты: а) зур музыкаль-сәхнә һәм вокаль әсәрләр өчен, б) зур инструменталь әсәрләр өчен, в) кече музыкаль форма әсәрләре өчен, г) концерт-башкару эшләре өчен. Шуның өстенә, СССР Халык Комиссарлары Советы үзенең бу карарында сәнгать һәм әдәбият өлкәсендә күп еллар буена күренекле казанышлары өчен Сталин исемендәге өстәмә премияләр бирүне күздә тотты.

Казан шәһәренең Осоавиахим бешмаларындагы техник элемтә курсларында йөзләп кеше укып чыкты һәм радистоператор квалификациясе алды. Хәзер бу курсларга 9—10 нчы класс укучылары йөриләр. Рәсемдә (сулдан уңга): 7 нче номерлы мәктәп укучыларыннан М. Иванова, В. Иванова, О. Романова һәм инструктор М. Семенова иптәшләр. К. Тахтеев фотосы.

# ССР СОЮЗЫ ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## Сәнгать һәм әдәбият өлкәсендә 1942 нче елда булган күренекле эшләр өчен Сталин исемендәге премияләр бирү турында

(Ахыры. Башы 1 нче биттә)

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премия**

1. Константин Михайлович Симоновка—«Рус кешеләре» пьесасы өчен.

### II. СӘНГАТЬ ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ КҮРЕНЕКЛЕ КҮП ЕЛЛЫК КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН

**100.000 сум күләмендәге беренче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Владимир Иванович **Немирович-Данченкога**—СССР ның халык артисты.
2. Василий Иванович **Качаловка**—СССР ның халык артисты.
3. Иван Михайлович **Москвинга**—СССР ның халык артисты.
4. Ольга Леонардовна **Книппер—Чеховага**—СССР ның халык артисткасы.
5. Михаил Михайлович **Тархановка**—СССР ның халык артисты.
6. Антонина Васильевна **Неждановага**—СССР ның халык артисткасы.
7. Ксения Георгиевна **Держинскаяга**—СССР ның халык артисткасы.
8. Александр Степанович **Пироговка**—СССР ның халык артисты.
9. Надежда Андреевна **Обуховага**—СССР ның халык артисткасы.
10. Екатерина Васильевна **Гельцерга**—РСФСР ның халык артисткасы.
11. Александра Александровна **Яблочкинага**—СССР ның халык артисткасы.
12. Варвара Николаевна **Рыжовага**—СССР ның халык артисткасы.
13. Вера Николаевна **Пашеннаяга**—СССР ның халык артисткасы.
14. Александр Алексеевич **Остужевка**—СССР ның халык артисты.
15. Пров Михайлович **Садовскийга**—СССР ның халык артисты.
16. Евдокия Дмитриевна **Турчаниновага**—РСФСР ның халык артисткасы.
17. Екатерина Павловна **Корчагина-Александровскаяга**—СССР ның халык артисткасы.
18. Юрий Михайлович **Юрьевка**—СССР ның халык артисты.
19. Вера Аркадьевна **Мичурина-Самойловага**—СССР ның халык артисткасы.
20. Константин Федорович **Юонга**—РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе.
21. Петр Петрович **Кончаловскийга**—РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе.
22. Викентий Викентиевич **Вересаевка**—язучы.
23. Александр Серафимович **Серафимовичка**—язучы.

**50.000 сум күләмендәге икенче дәрәҗәдәге премияләр**

1. Борис Владимирович **Асафьевка** (Игорь **Глебовка**)—РСФСР ның халык артисты.
2. Иван Николаевич **Павловка**—художник-гравер, РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе.
3. Василий Николаевич **Бакшеевка**—художество рәсемнәре академигы, РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе.
4. Евгений Евгеньевич **Лансерега**—художество рәсемнәре академигы.
5. Никандр Сергеевич **Ханаевка**—РСФСР ның халык артисты.
6. Фаина Васильевна **Шевченкога**—РСФСР ның халык артисткасы.

**ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы Председателе И. СТАЛИН.**

**СССР Совнаркомы эшләрен идарә итүче Я. ЧАДАЕВ.**

# АЛДЫНГЫ ЦЕХТА

Цех стеналары буенда яхшы һәм уңай урнаштырылган витриналарда—художниклар тарафыннан бик яхшы язылган лозунглар, социалистик йөкләмәләр, ярыш барышы турында диаграммалар, участокларның, бригадаларның һәркөн алмашынып, үсеп бара торган күрсәткечләре, артта калучыларны әйдәүдә реаль нәтиҗә бирүче «Внук крокодила» каррикатуралары, цех алдынгыларының фоторәсемнәре...

Болар барысы да Н-че заводның парторгы иптәш Беляев булган цехында производство тормышының, ярышып эшләүнең чын көзгесе, әйбәт эшләүне, гел алга омтылуны күрсәтүче көзгесе булып торалар.

Цех беренче Май алды ярышына март башында ук кушылды. Алынган йөкләмәләр бөтенесенең күз алдында, витринада: март ае планын 105 процентка үтәргә, бракны, февраль ае белән чагыштырганда, 20 процентка киметергә, 5 рационализация тәкъдиме булдырырга, җиһазларны, инструментларны отлично хәлдә тотарга һ. б.

Бирелгән вәгъдәләр, алынган йөкләмәләр намус белән үтәләләр. Цех март аенда планнарны һәркөн саен арттырып үтәп килә. Мастерлары Фурман, Грузанов, Смирнов, Веденеев булган участоклар ярышта алдынгы булып баралар. Алар көндәлек производство программаларын системалы рәвештә 105—115 процентка үтәп киләләр.

15 нче мартка кадәр 4 рационализация тәкъдиме алынды һәм аларның 2 се тормышка да ашырылды инде. Беренче Май алды ярышына кушылып алынган башка йөкләмәләр дә арттырып үтәләләр.

# СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

## 20 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

20 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть сугышчылары Днепр елгасын кичтеләр һәм дошманның бер терәк пункты өчен булган сугышта 200 дән артык гитлерчыны кырдылар. 4 орудие, берничә дистә винтовка һәм пулеметлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең частьлар немецларның бер батальон пехотасын чолгап алдылар һәм бөтенләй юк иттеләр.

* * *

Төньяк Донецның урта агымы районында безнең гаскәрләр дошман танкларының һәм пехотасының зур көчләренең атакаларын кире кайтардылар. Бер участокта немецларның бер полк пехотасы, 25 танк ярдәме белән, атака ясады һәм зур югалтулар исәбенә безнең подразделениеләрне бераз кысрыклый алды. Н-че часть сугышчылары, үзләренең көчләрен яңадан оештырып, гитлерчыларга контратака ясадылар һәм аларны элекке позицияләренә алып ташладылар. Дошманның 5 танкысы, танкка каршы ата торган 9 орудиесе һәм 500 гә якын солдат һәм офицерлары юк ителде. Икенче бер участокта совет артиллеристлары һәм минометчиклары дошманның 2 авыр орудиесен, аларның расчетларын, 3 танкысын һәм сугыш припаслары төялгән кимендә 20 автомашинасын юк иттеләр.

* * *

Ильмень күленнән көньяктарак Н-че берләшмә частьлары, алга таба барып, дошманны халык яши торган бер пункттан бәреп чыгардылар. Урам сугышында безнең сугышчылар бер ротага якын гитлерчыларны кырдылар. Икенче бер участокта совет подразделениеләре немецларның бер терәк пунктын тар-мар иттеләр. Бу пункт өчен булган сугышларда 6 орудие, 10 пулемет, берничә дистә винтовка һәм бер сугыш припаслары склады кулга төшерелде. Пленныйлар алынды.

* * *

Киев өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды халык яши торган һәм немецларның полицейскийлар ротасы урнашкан бер пунктны чолгап алган. Совет патриотлары бик каты сугышта барлык гитлерчыларны кырып бетергәннәр. Партизаннарны бастыру өчен немецлар күрше гарнизоннан берничә подразделение җибәргәннәр. Ләкин партизаннарга вакытында кисәтү ясалган һәм килеп җиткән гитлерчыларны партизаннар пулемет уты белән каршы алганнар. Дошман юлда дистәләрчә үле гәүдәләр калдырып чигенгән. Партизаннар 17 пулемет, 12[illegible] винтовка, 8 мең патрон һәм 7 автомашина кулга төшергәннәр.

* * *

Түбәндә Калинин өлкәсе, Брехово авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турында акт игълан ителә: «Январь башында немец оккупантлар Брехово авылында концентрация лагере ясадылар һәм шунда тирә-як авыллардан 1.000 ләп кешене куып китерделәр. Аларны сарайларга һәм амбарларга урнаштырдылар. Гитлерчылар лагерьдагы тоткыннарны тәүлегенә 18 әр сәгать эшләргә мәҗбүр иттеләр һәм ачлык белән газапладылар. Ике ай эчендә лагерьда ачлыктан һәм кыйналудан 400 дән артык кеше үлде. Немец бандитлар авыл халкыннан бер группа ирләрне һәм хатын-кызларны сайлап алып, аларны балаларыннан аердылар һәм ирексезләп Германиягә каторгага озаттылар. Ятим калган балаларны немецлар аерым бер сарайга яптылар һәм анда беркемне дә кертмәделәр. Күп балалар ачлыктан һәм салкыннан үлде. Кызыл Армия частьлары авылны алганда сарайда бары 29 бала калган иде. Алар берсе дә йөри алмыйлар һәм сөяккә генә калганнар иде». Актка Евдокия Виноградова, Иван Лаптухов, Анастасия Голосова, Александра Соколова, Анна Брусничкина, Прасковья Вышиславцева һәм башкалар кул куйды».

* * *

Франция тимер юлларында саботаж һәм диверсия актлары саны бик нык арткан. Франция патриотлары немец оккупантлар файдалана торган коммуникацияләргә көн саен сизелерлек ударлар ясыйлар. Марсель районында бер атна эчендә немецларның сугыш йөкләре төялгән 6 поезд юлдан чыгарылган. Лион янында тимер юлчылар немецларның бер хәрби эшелонын товар поездына бәрелдерүне оештырганнар. Париж районында февраль аенда гына да 68 паровоз сафтан чыгарылган.

# Рационализаторлар киңәшмәсе

Н-че заводта рационализация һәм уйлап табучылык эше киң җәелдерелгән. Бу өлкәдә үткән елдагы күренекле уңышлар өчен завод коллективы Наркомат күләмендәге ярышта 2 нче урынны алды (1 нче урынны бирәү дә ала алмады) һәм нарком тарафыннан махсус приказ белән акчалата бүләкләнде.

Заводның рационализаторлары, уйлап табучылары һәм, гомумән, барлык коллективы алдында 1943 нче елда яңа җитди бурычлар тора. 15 нче мартта үткәрелгән конференция нәкъ менә шул үткән елдагы рационализация һәм уйлап табучылык эшләренә йомгак ясау һәм 1943-нче елга практик бурычлар билгеләү мәсьәләсенә багышланды.

Конференциядә докладны заводның баш инженеры иптәш Кадышев ясады.

— Заводыбызның рационализаторлары һәм уйлап табучылары узган елны,—ди иптәш Кадышев,—сугыш чоры таләпләренә лаеклы рәвештә эшләделәр. 3 миллион 571 мең сум экономия бирә торган 90 тәкъдим алынды. Шулардан 39 ы тормышка ашырылды да инде. Шушылар нәтиҗәсендә без дефицитлы күп кенә материалларны бүтән материаллар белән алмаштыра алдык, производствоның технологиясен яхшырттык, чималга, материалларга шактый экономия ясадык һ. б. Коптев, Макарычев, Амелин һ. б. иптәшләр гаять кыйммәтле тәкъдимнәр кerттеләр һәм алар заводның алдынгы рационализаторлары булып саналалар.

Доклад буенча фикер алышуларда Коптев, Домныч, Бибишева, Балабанов һ. б. иптәшләр чыгып сөйләделәр.

Докладта, фикер алышуларда һәм кабул ителгән карарда, узган елны рационализация өлкәсендә ирешелгән уңышларны ныгытырга һәм 1943 нче елда тагын да күбрәк энергия һәм иҗат көче белән эшләргә, дигән бердәм фикер чагылдырылды. Быел завод рационализаторлары алдына конкрет бурычлар куелды.

2—2,5 миллион сумлык экономия бирерлек 300—350 тәкъдим булдырырга.

Рационализация чаралары үткәрү, алмаштыргычлар куллану исәбенә хезмәт житештерүчәнлеген 10 процентка күтәрергә, продукциянең үзенә төшү бәясен 1 процентка киметергә һ. б.

Конференция ахырында заводның алдынгы рационализаторларын һәм уйлап табучыларын бүләкләүләр булды.

# Ржев тимер юл узелына ярдәм

Казан тимер юлының Юдино узелы комсомолецлары һәм союздан тыш яшьләре немец басып алучылардан азат ителгән Ржев тимер юл узелын аякка бастыру өчен кирәк булган запас частьлар һәм инструментлар әзерләү эшен башлап җибәрделәр.

Яшь юлчылар эш вакытыннан тыш барлыгы 200 данә төрле инструментлар—шаблоннар, кләшчәләр, чүкечләр һәм башкаларны әзерләделәр.

Юдино участогы вагончылары 1.000 нән артык бик әһәмиятле запас частьлар, депо паровозчылары сынау өстәле һәм 260 [illegible] төрле инструментлар ясадылар. Узелның яшь тимер юлчылары эвакуацияләнгән җиһазларны тәртипкә китерү буенча да зур эшләр башкаралар.

**I. ГУСЕВ.**

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

# Чәчүлек орлык туплау декадасы башланды

*Колхозчы массаның патриотик инициативасын хәрби уңыш өчен көрәшкә юнәлтик!*

## КОЛХОЗЛАРНЫҢ ОРЛЫК ФОНДЫНА

*Совет патриотлары взносы*

45. КЛИМЕНТЬЕВА С.—Яңа Писмән районы; «Вязовка» авыл хуҗалыгы артеле члены—20 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирде.

46. ТИХОНОВ В.—Яңа Чишмә районы, «Рассвет» колхозы председателе—18 пот ашлык һәм 18 пот бәрәңге бирде.

47. ГАЛИЕВ М.—Беренче Май районы, «Бүләк» колхозы члены—18 пот ашлык һәм 18 пот бәрәңге бирде.

48. ТИМОФЕЕВА А.—Кызыл йолдыз районы, «Восход» авыл хуҗалыгы артеле члены—18 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирде:

49. ТИМИРОВА С.—Яңа Писмән районы, «Вязовка» авыл хуҗалыгы артеле члены—18 пот ашлык кертте.

50. ПАВЛОВ И.—Балтач районы, Киров исемендәге колхоз члены—25 пот ашлык һәм 2 центнер бәрәңге кертте.

51. ХАББАНОВА Х.—Азнакай районы, «Кызыл байрак» колхозы члены—12 пот ашлык кертте:

52. БАХАЛОВА К.—Азнакай районы, «Кызыл байрак» колхозы члены—9 пот ашлык кертте.

53. ГАТАУЛЛИН Г.—Азнакай районы, «Кызыл байрак» колхозы члены—8 пот ашлык кертте.

54. ХӘБИБУЛЛИН В.—Азнакай районы, «Кызыл байрак» колхозы члены—8 пот ашлык бирде.

«Ударник» колхозында (Арча районы) колхозчыларның үз хуҗалыкларындагы запастан чәчү орлыгы туплауда актив катнашучы колхозчы Җәләли иптәш Җамалиев.

И. Папков фотосы.

## ВӘГЪДӘБЕЗНЕ ҮТӘРБЕЗ

Минзәлә районының колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары быел югары иген уңышы алырга батыр фронтовикларга һәм туганыбыз Сталинга вәгъдә бирделәр. Алар үзләренең вәгъдәләрен намус белән үтәргә тырышалар.

Районның кайбер колхозларында язгы чәчү өчен орлык җитешми иде. Алдынгы кешеләрнең, үз хуҗалыкларындагы запасларыннан орлык өчен ашлык биреп торулары —гүзәл патриотик чыгышлары бездә урында орлык әзерләү мөмкинлеге барлыгын күрсәтте.

«Яңа юл» колхозы члены, авыл советы депутаты Хәбибә иптәш Хикмиева орлык фондына 222 пот ашлык бирде. Гәрәй иптәш Шәйхетдинов 73 пот ашлык бирде. Биредә колхозчылардан барысы 1.738 пот чәчүлек орлык тупланды.

75 яшьлек карт колхозчы үзенең хуҗалыгындагы запасыннан «Алга» колхозының орлык фондына 61 пот ашлык биреп торды. Иптәш Сабиров та 52 пот ашлык китерде һәм колхоз правлениесенә, яңа уңыштан бу ашлыкны кире кайтару турындагы йөкләмә тәкъдим ителгәч, ул:

— Миңа ышаныч язуы кирәкми. Колхоз үземнеке. Үзем-үзем бирәм,—дип йөкләмәне алмады.

«Ык буе» колхоз члены, фронтовик хатыны иптәш Әхмәтҗанова күптән түгел иреннән хат алды. Колхозчы-сугышчы хатында каты сугышта 10 тапкыр катнашып аның һәркайсысында гитлерчыларны бик нык кыйнавы турында язган иде. Иптәш Әхмәтҗанова колхозга 30 пот чәчүлек орлык биреп:

— Нәләт суккан фашистларны кыйнауда минем катнашым шушы булсын,—диде.

«Кызыл йолдыз» колхозында 4 фронтовик егетләрнең атасы булган иптәш Хәбибуллин 61 пот ашлык бирде. Самолетлар эскадрильясы төзү фондына 100 мең сум акча керткән иптәш Әхметов орлык фондына 40 пот ашлык бирде.

Чын патриотларның исемлеге бик озын. Колхозчылардан 83 кеше 30 ар поттан да ким бирмәделәр. Районның күп кенә колхозларында бу хәрәкәт киң җәелде: Тиз арада район буенча 1.121 центнер ашлык, 1.600 центнер бәрәңге җыелды.

Районда язгы чәчүгә әзерлекне һәм чәчүлек орлык туплауны без ничек оештырдык соң?

ВКП(б) Өлкә Комитетының IX пленумы карарларын район партия җыелышында, комсомол активы һәм колхозчылар җыелышларында яхшылап өйрәнелде. Бу карарларны практик рәвештә тормышка ашыру өчен район активыннан колхозларга йөздән артык кеше җибәрелде. Без төп игътибарны чәчүлек орлыкны әзерләп бетерүгә юнәлттек. Барлык колхозларда орлык әзерләү буенча махсус бригадалар төзелде. Бригада членнары үз хуҗалыкларындагы запасларыннан орлыклык ашлык тапшырып иң элек үзләре үрнәк күрсәтteләр. Алар колхозчылар арасында аңлату эшләре алып баралар. Колхозчылар белән беседалар үткәрәләр. Колхоз кырларын чәчүлек орлык белән тәэмин итүнең әһәмиятен колхозчыларга аңлаталар.

Колхозларда кырчылык бригадаларына язгы чәчүнең планын үтәү буенча заданиеләр җиткерелде. Заданиеләрне үтәү буенча бригадалар үзара ярышалар һәм беренче чиратта чәчүлек орлык булдыру турында кайгырталар.

Алдынгы колхозчыларның инициативасын котлап, ВКП(б) Өлкә Комитеты һәм Совнарком тарафыннан бирелгән телеграмма безне тагын да тырышыбрак эшләүгә, якын көннәрдә чәчүлек орлыкны әзерләп бетерүгә туплады. Без вәгъдәбезне үтәрбез.

**Х. ХӘКИМҖАНОВ,**
ВКП(б) райкомы секретаре.

## ЧАКЫРУГА КУШЫЛЫП

Молотов исемендәге колхозда (Биектау районы) Апас районы колхозчыларының чакыруы хезмәт җитештерүчәнлеген нык күтәрде. Фронт айлыгында үткәрелергә тиешле эшләр конкрет рәвештә планлаштырылды. Колхозда җирле ашламалар әзерләү эше акрын бара иде. Хәзер моңа нык әһәмият бирелә. Айлыкта 220 йөк тирес чыгарылды, 3 центнер көл җыелды. Укучы балалардан төзелгән отряд ашламалар җыюны әле дә дәвам итә. Һәрбер колхозчы хуҗалыгында да көл һәм кош тизәге җыела.

Тимерче иптәш Данилов авыл хуҗалыгы коралларына ремонтны 25 нче мартта тәгәлләргә йөкләмә алган иде. Хәзер инде ремонт тәгәлләнеп килә.

Урында чәчүлек орлык туплау буенча күп кенә чаралар күрелде. Вика һәм борчак орлыгы җитешми иде. Азык өчен калдырылган борчактан яхшыларын сайлап алу һәм начар сугылган вика саламын яңадан сугу юллары белән шактый орлык арттырылды. Кайбер культуралар буенча орлык башка колхозлардан алмаштырып алынды. Орлык өчен 3 центнер бәрәңге кисентеләре җыелды.

**С. ДИМИТРОВ.**

## Колхозчылар булышлыгы

КАЙБЫЧ, 20 март. (Телефон буенча). «Гигант» колхозында чәчү орлыгы әзерләүне тәгәлләү уңышлы башланды. Колхоз члены Мөнирә иптәш Хөснетдинова үзенең запасыннан 2 центнер ашлык, бер центнер бәрәңге бирде. Колхоз председателе иптәш Козлов бер центнер ашлык, 2 центнер бәрәңге тапшырды. Колхозчы Алимов бер центнер орлык һәм бер центнер бәрәңге биреп торды. Кыска гына вакыт эчендә колхозда 16,5 центнер ашлык, 94 центнер бәрәңге җыелды.

15 хуҗалыктан гына торган «Красная заря» колхозчылары да бер көн эчендә чәчүлек өчен 6 центнер ашлык, 15 центнер бәрәңге җыйдылар. Колхозчы иптәш Родионов 8 пот ашлык һәм 6 пот бәрәңге бирде.

**Г. КУШАЕВ.**

## Күңел хушландырырлык эш булмагач...

«Март ае яз башыдыр, күңелне хуш ясыйдыр» дип җырлаган шагыйрь Габдулла Тукай. Ләкин һәрбер кеше өчен дә алай түгел икән шул. Март аеның беренче көннәре Әхмәмәт МТС ы директоры иптәш Алимовның күңелен хушландырмады. Ремонтның барышын күрсәткән сводкада МТС 12 нче урында тора иде. Мартта 85 нче урынга төште. Ни өчен болай булды соң әле бу, дип уйлады да ул:

— Запас частьлар җитешми шул,—дип юанды. Шушы ук вакытта, политбүлек начальнигы иптәш Мамин да уйга чумган иде. Аны да:

— Ни өчен ремонт планының үтәлеше 53 проценттан артмый?—дигән сорау борчыды.

Ул да:

— Эх, кадрларның күбесе яңа шул,—дип авыр сулады.

МТС тагы ике хуҗаны да запас частьларның җитешмәве һәм кадрларның яңа булуы нык кына борчыды ахыры, аларга бик күңелсез булып китте.

Ремонтны тәгәлләргә вакыт!

Бу таләп аларны бөтенләй хәлсезләндерде. Гамьсез йөрәк ярсыды. МТС ның аерым участоклары күз алдына килеп басты.

Менә ремонт мастерское. Биредә кәкре-бөкре сынлы үтмәс инструментлар теләсә кайда аунап яталар. Станоклар шакшы, чүп-чар арасында күмелеп калган шикелле күренәләр. Ишек алдында тагын кызганычрак хәл: машиналар, сабаннар кар астында. Тик март кояшы рәхимле бит ул. Машиналарны каплаган кар эреп юкарган, кайда, нинди инвентарьлар барын белеп була.

МТС усадьбасы шундый күңелсез. Биналарда бертөрле дә тәртип юк. Кечкенә генә лозунг яки плакат та күренми дияр идең, бер урында—ускереп беткән, моннан 3 ел элек язып эленгән барыбы тик бер плакат кына асылынып тора. Стена газеталарының урыннары буш.

Шушындый кимчелекләр барысы да кинәт күз алдына килеп баскач җитәкчеләр үзләре дә, куркыныч төш күргән кеше шикелле, урыннарыннан сикереп торалар...

— Бу эшләрне тәртипкә салу өчен нинди запас частьлар кирәк соң әле?—дигән сорау үзеннән-үзе килеп туа.

Ләкин бу өлкәдә запас частьлар сәбәп була алмыйлар шул. Саксызлык, гамьсезлек аркасында килеп туган хуҗасызлыкка каршы көрәшү өчен бернинди дә запас частьлар кирәкми, әлбәттә. Хуҗасызлыкны, җанлы кешеләр белән эшләмәүне, машиналарны, инвентарьны саклап тотмауны тышкы күренеше үк күрсәтеп торган МТС тан нәрсә көтәргә кирәк соң? Бу кимчелекләрне бетермәгәндә запас частьлар да табылмас, яңа кадрлар да эшкә өйрәнә алмаслар. Нәкъ менә һәрбер участокта эшне большевикларча кайгыртучанлык белән оештырмаганга да Әхмәмәт МТС ы һаман бер урында таптанып торудан уза алмый бит! Алимов һәм Мамин иптәшләр үзләре моны аңлыйлармы? Район җитәкчеләре МТС тагы бу хәлгә ничек түзеп торалар?

**М. НУРЕТДИНОВА.**

## ЭШ ӨЗЕКЛЕКТӘ

НОРЛАТ, 20 март. (Телефон буенча). Сабанга чыгарга санаулы көннәр генә калды. Инде чәчүлек орлык күптән әзерләнеп куелган, тишелеше тикшерелеп каралган булырга тиеш иде. Ләкин «Кызыл алан» колхозы бу турыда начар кайгырта. Биредә чәчүлек орлык әзерләү эше өзеклектә. Колхозга 989 центнер чәчүлек орлык кирәк. Аның 286 центнеры гына әзерләнгән әле.

Колхоз җитәкчеләре (председателе иптәш Шиһапов) чәчүлек мәйданын орлык белән тәэмин итү турында кайгыртмыйлар. Җитешмәгән орлыкны колхозчылардан бурычка алып торуны оештырмыйлар. Бу мәсьәлә буенча бертөрле дә эш алып барылмый.

Яшелчә һәм бәрәңге орлыклары әзерләүгә дә әһәмият бирүче юк. Җитәкчеләр яшелчә орлыкларын базардан сатып алырбыз әле дип тынычланганнар. Чәчү вакытында базардан-базарга чабып, вакытны бушка үткәрергә уйлыйлар ахыры.

**Р. ХӘСӘНОВА.**

## ИКМӘКНЕ ӘРӘМ-ШӘРӘМ ИТҮ ФАКТЛАРЫН БЕТЕРЕРГӘ

Ватан сугышы шартларында икмәкне һәм башка азык продуктларын экономия белән тоту мәсьәләсе аеруча зур әһәмияткә ия булып тора. Шуңа да карамастан, күп кенә сәүдә һәм икмәк пешерү оешмаларында онны һәм икмәкне әрәм-шәрәм итү фактлары еш кына очраштырганлый.

Заготзерноның Татарстан республика конторасы инспекторлары тарафыннан тикшерүләр ясалгач, күп кенә сәүдә һәм икмәк пешерү оешмаларында икмәкне тотуда җавапсызлык һәм хуҗасызлык фактлары ачылды. Росглавхлебның икмәк заводлары һәм пекарнялары 1942 нче елның IV кварталында Казан шәһәрендә 470.095 килограмм икмәкне законсыз тотканнар. Шул исәптән аларның үз транспортлары өчен нормадан тыш 31.000 килограммнан артык, ашханәләре өчен 18.574 килограмм икмәк тотылган.

Чистайдагы «Восход» артелендә ноябрь аенда атларга ашату өчен 103 килограмм, декабрь аенда 412 килограмм арыш оны һәм этләрне туйдыру өчен 61 килограмм пешкән икмәк тотылган.

Главмуканың Смыловкадагы тегермәне директоры Макаров IV кварталда үзенең сотрудникларына нормадан тыш 158 килограмм бодай оны өләшкән, Ширәмәт лесхозына 500 килограмм, Сокольский лесхозына 300 килограмм он саткан һәм 200 килограмм онны иткә алмаштырган.

Заинский райпотребсоюзында үткән елның октябреннан алып, шушы елның 1 нче февраленә кадәр райпотребсоюз председателе Хәйруллинның кушуы буенча 170 килограмм арыш оны, 503 килограмм бодай оны һәм 813 килограмм пешкән икмәк законсыз рәвештә төрле кешеләргә бирелгән. Заинский сельпосының элекке председателе Тарасов 165 килограмм онны һәм 655 килограмм пешкән икмәкне төрле кешеләргә өләшкән.

Главмуканың Чаллыдагы тегермәнендә, Респторгның Чаллы бүлегендә, Красный бор районының Исәнбай сельпосында һәм башка күп кенә оешмаларда да икмәкне әрәм-шәрәм итү фактлары ачылды. Татарстан Сәүдә халык комиссариаты, Татсоюз һәм Росглавхлебның Татарстан конторасы икмәкне экономия белән тоту мәсьәләсенә җитәрлек дәрәҗәдә әһәмият бирмиләр, сәүдә һәм икмәк пешерү оешмаларына контроль ясамыйлар. Шунлыктан күп кенә оешмаларның җитәкчеләре икмәкне һәм башка продуктларны әрәм-шәрәм итүдә дәвам итәләр. Кайбер сәүдә оешмаларында сатылган икмәк өчен киселә торган карточка талоннары 2—3 ай буена тикшерелми. Шуның нәтиҗәсендә азык продуктларын урлау өчен киң мөмкинлек бирелә.

Хөкүмәт карары нигезендә барлык сәүдә һәм икмәк пешерү оешмалары Заготзерно пунктларыннан ала торган ашлыкны нинди урыннарга тотулары турында тулысынча отчет бирергә тиешләр. Ләкин Татсоюз председателе иптәш Осинцев һәм Росглавхлеб тресты управляющие иптәш Финкельштейн, төрле сылтаулар табып, отчетларны үз вакытында бирүне өзеп киләләр. Шуның белән алар икмәкне һәм башка азык продуктларын әрәм-шәрәм итүгә һәм урлауга юл куялар. Бу җитешсезлекләр кичекмәстән бетерелергә тиеш. Барлык оешмалар Заготзерно складларыннан ала торган ашлыкны нинди урыннарга тотулары турында кичекмәстән отчет биреп барырга тиешләр. Икмәкне әрәм-шәрәм итүчеләрне каты җавапка тартырга кирәк.

**Ф. ИОНОВ,**
Заготзерноның Татарстан конторасы управляющие.
**П. НИКИШКИН,**
Татарстан АССР уполнаркомзагы.

# СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

## 20 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРУ

20 нче мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

19 нчы мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 20 гә якын танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 150 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 16 кыр һәм зенит артиллериясе батареяларының утын бастырдылар, 5 сугыш припаслары складын шартлаттылар, 2 тимер юл составын җимерделәр.

* * *

Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че берләшмә частьлары штурм ясап, дошман оборонасының бер терәк пунктын алдылар. Бу пункт өчен булган сугышларда 400 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Пленныйлар алынды. Икенче бер участокта немецлар пехота һәм танк көчләре белән контратака ясадылар. Безнең гаскәрләр, барлык төр кораллардан ут ачып, гитлерчыларның атакаларын кире кайтардылар һәм аларны зур югалтуларга дучар иттеләр.

* * *

Белый шәһәреннән көньякта безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть подразделениеләре немецлар тарафыннан көчле итеп ныгытылган халык яши торган бер пунктның флангларына барып чыктылар һәм аңа ике яклап атака ясадылар. Каты бәрелешләрдән соң дошман гарнизоны, 5 орудиесен һәм 20 автомашинасын ташлап калдырып, чигенә башлады. Безнең гаскәрләр, чигенүче гитлерчыларны куа барып, дошманның 300 гә якын солдат һәм офицерын юк иттеләр. Пленныйлар һәм бик күп кораллар кулга төшерелде.

* * *

Чугуев районында безнең частьлар бик каты оборона сугышлары алып бардылар. Н-че берләшмә сугышчылары бер көн эчендә, дошманның атакаларын кире кагып, 16 немец танкысын, 12 бронемашинасын, 2 самоход орудиесен, 60 автомашинасын һәм 800 дән артык солдат һәм офицерларын юк иттеләр. Танкларга утырган бер группа немец автоматчиклары халык яши торган бер пунктка бәреп керергә маташтылар. Дошман танклары без миналаган кырга килеп эләктеләр һәм, үзләрендәге барлык гитлерчылары белән бергә, шартлап һавага күтәрелделәр.

* * *

Ильмень күленнән көньякта безнең частьлар дошманның көчле итеп ныгытылган позицияләрен алдылар. 4 орудие, 7 миномет, 15 пулемет, 1 радиостанция һәм 1 сугыш припаслары склады кулга төшерелде. Икенче бер участокта кул сугышларында безнең бер подразделениебез немецларның күпер алдындагы ныгытмаларын саклап торучы ике взводын юк иттеләр.

Башында майор иптәш Сурков торган сигез совет очучы-истребительләре безнең гаскәрләрнең сугышчан тәртипләрен бомбага тотарга маташкан 20 немец бомбардировщигына каршы атака ясадылар. Немец очучылары качып киттеләр. Совет истребительләре, гитлерчыларны куа барып, 7 немец самолетын бәреп төшерделәр һәм бернинди югалтусыз үз аэродромнарына кайттылар.

* * *

Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды 7 нче мартта, засададан торып, бер колонна немец мотоциклчыларына ут ачканнар. Партизаннар 57 дошман солдатын һәм офицерын юк иткәннәр. Берничә дистә мотоцикл, автоматлар, винтовкалар һәм 3.000 патрон кулга төшергәннәр. Икенче бер отрядның партизаннары 10 нчы мартта дошманның бер тимер юл эшелонын юлдан чыгарып аударганнар. Бер паровоз һәм йөкләр төялгән 30 вагон җимертелгән.

* * *

Волхов фронтының бер участогында 132 нче немец пехота дивизиясенең составындагы 437 нче полкның 1 нче ротасыннан плен алынган солдат Людвиг Дангес түбәндәгеләрне сөйләде: «Безнең полк Севастополь янындагы сугышларда катнашкан иде. Анда ул чиксез зур югалтуларга дучар ителде. Рота составыннан нибары берничә кеше генә исән калган иде. Июль аенда ротага яңадан 100 кеше өстәделәр һәм безне Синявино районына күчерделәр. Көз көне руслар безне яңадан тар-мар иттеләр һәм рота командиры лейтенант Брайнбахны үтерделәр. Ротада нибары 10 кеше калды. Беркадәр вакыттан соң безгә тагын да 90 солдат һәм 8 унтер-офицер өстәделәр. Күптән түгел без оборона сугышы алып барган идек. Рус танклары безне чолгап алдылар. Инде артык каршы тору бөтенләй мәгънәсез булачак иде. Ротаның калдыклары, обер-лейтенант Креммер белән бергә, пленга бирелделәр. Шулай итеп, бер елдан да ким вакыт эчендә рота бөтен кешеләр составын 3 тапкыр югалтты һәм хәзер инде бөтенләй юкка чыкты».

Азат ителгән Великие Луки шәһәрендә. Рәсемдә: сугышчы «һаваны» күзәтә.

ТАСС. фотохроникасы.

## СОВЕТЛАР СОЮЗЫНДА

### Сталинградны төзекләндерү фондына ике пот алтын

Лена тау эшчеләре һәм старательләре алтын промышленносте яшәвенең 100 еллыгын һәм Лена вакыйгаларының 31 еллыгын билгеләп үтәргә әзерләнәләр.

Бу даталарны билгеләп үтүгә әзерлек производствода яңа күтәрелеш белән бара. Лензолото трестының предприятиеләре март аеның беренче декадасында алтын табу планын арттырып үтәделәр.

Приискларның старательләре 10 нчы мартка кадәр 2 пот алтын җыярга һәм аны Сталинград заводларыннан берсенә җиһазлар алу өчен хөкүмәткә түләүсез тапшырырга йөкләмә алдылар.

* * *

Быел яңадан 5 фронт театры оештырыла. Сәхнә мастерларыннан 25 кеше иҗади отчетлар белән фронтларга чыгачаклар. Һәр ай саен фронтларның аерым участокларында кимендә 40 концерт бригадалары булачак. Азат ителгән районнарга хезмәт күрсәтү өчен берничә дистә бригада оештырыла. (ТАСС).

# ШВЕЦИЯ НЕЙТРАЛИТЕТЫН БОЗУ

СТОКҺОЛЬМ, 19 март. (ТАСС). Швеция газеталарының хәбәр итүләренә караганда, 24 нче февральдә Швециянең Вермланд провинциясенең төньяк-көнбатыш районына Германиянең бер почта самолеты «иректән килеп төшкән». Аның пассажирлары—хәрби формадагы коралы 15 немец һәм медицина сестрасы—Норвегиягә озату өчен Швеция офицерлары сакчылыгы астында Шарлотенберг шәһәренә җибәрелгәннәр. Чикне үтеп чыккан вакытта Швеция властьлары аларның коралларын кайтарып биргәннәр. Алар очып килгән самолетта пулеметлар да булган. Газеталарда язылган хәбәрләрдән ачык күренгәнчә, Швеция белән Германия арасында ясалган килешү буенча, немецларның почта самолетларына Норвегия белән Финляндия арасында Швеция территориясе өстеннән үтеп йөрергә рөхсәт ителә. Кайбер хәлләрдә бу самолетларга Стокһольмның Бромм аэропорты аркылы очарга һәм шунда төшәргә дә мөмкин.

«Нюа даглигт аллеханда» газетасының хәбәр итүенә караганда, чит ит эшләре министры Гюнтер рейхстагта депутат Иенссон тарафыннан бирелгән сораугa түбәндәге җавапны биргән: «Швеция нейтралитеты кагыйдәләре буенча, сугышучы державаларның хәрби самолетлары Швеция территориясенә очып керәскә тиешләр. Шуңлыктан почта самолетларына бары тик коралсыз булганда гына очарга рөхсәт ителә. Аларның экипажлары хәрби кешеләр булмаска һәм самолетлар үзләре коралсыз булырга тиешләр. Ләкин 24 нче февральдә килеп төшкән самолетта 2 пулемет булган»:

Гюнтерның әйтүенә караганда, Швеция хөкүмәте бу турыда немец властьларына хәбәр иткән һәм Швеция өстеннән почта самолетларын үткәрү турындагы кагыйдәләрне җиренә җиткерергә кирәклекне күрсәткән.

Депутат Иенссон Гюнтерның бу җавабы җәмәгатьчелек фикерен канәгатьләндерүе шикле дип белдергән.

Депутат Хагбернның әйтүенчә, самолет төшкән урындагы патруль сугыш патроннарын алмаган. Немецларны коралсызландырмаганнар һәм Швеция властьларына самолетка керергә рөхсәт ителмәгән. Немецлар үзләренең бөтен багажларын алганнар һәм аларның икесе самолетны саклау өчен шул урында калган. Самолетта коралы офицерларның булуы ике арадагы килешүне ачыктан ачык бозган булса да, хөкүмәт бу турыда бер төрле дә чара күрмәгән. Швеция командованиесе самолетта пулеметлар булганлыгын иң соңгы моментка кадәр чит ил эшләре министрлыгыннан яшереп килгән.

## АМЕРИКА АВИАЦИЯСЕНЕҢ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 19 март. (ТАСС). Рәсми хәбәрләргә караганда, кичә көндез белән Американың авыр бомбардировщиклары берләшмәләре Фегезакта (Төньяк Көнбатыш Германия) Германиянең су асты көймәләре верфьләренә зур һөҗүм ясаганнар. Бомбаларның туп-туры төшүләре күренгән.

Фигезак Бременнан 15 миль төньяк-көнбатыштарак су асты көймәләре төзелеше һәм ремонт буенча Германия верфьләренең иң зурларыннан берсе.

## АМЕРИКА АВИАЦИЯСЕНЕҢ НЕАПОЛЬГӘ ҺӨҖҮМЕ

НЬЮ-ЙОРК, 19 март. (ТАСС). АКШ һава көчләре штабының Каһирәдән хәбәр итүенчә, 18 нче мартта көндез һәм 19 нчы мартка каршы төндә Американың авыр бомбардировщиклары Неаполь гаванена һөҗүмнәр ясаганнар.

## Урта диңгездә күчәр державаларының корабльләрен батыру

ЛОНДОН, 19 март. (ТАСС). Диңгез министрлыгының хәбәр итүенчә, Англиянең Урта диңгездә хәрәкәт итә торган 2 су асты көймәсе 10 көн эчендә дошманның 10 кораблен батырганнар.

## ФРАНЦИЯ ПАТРИОТЛАРЫНЫҢ ОККУПАНТЛАРГА КАРШЫ КӨРӘШЕ

ЛОНДОН, 19 март. (ТАСС). Газеталарга алынган хәбәрләргә караганда, Югары Савойя тауларында партизан отрядларының каршылык күрсәтүләре өзлексез кечәя бара. Немецлар аларга каршы көрәшү өчен бронетанк көчләреннән файдаланырга маташканнар. Ләкин партизаннар Тонон янындагы тауны җимергәннәр. Нәтиҗәдә моторлаштырылган гаскәрләр өчен тау буйларына үтеп керә торган юл бикләнгән. Таудагы барлык юлларда баррикадалар ясалган.

Ун меңнәрчә французлар Германиягә эшкә барудан котылу өчен, илнең төрле районнарында яшеренеп йөриләр. Франциянең үзәк районнарындагы тауларда соңгы вакытта әһәмиятле тимер юл магистральләрендә саботаж актлары бик еш була башлаган. Франциянең көньягында да гитлерчыларның чараларына каршылык күрсәтү торган саен көчәя бара.

Югары Савойя авылларында, тауларда яшеренгән патриотларны азык белән тәэмин итә торган крестьяннарны күпләп кулга алулар башланган.

## Франция Гвианасының генерал Жирога кушылу

ЛОНДОН, 19 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Франция Гвианасы (Көньяк Американың төньяк ярлары буенда Франция колониясе) генерал Жирога кушылган.

## БЕЛДЕРҮ

— Шушы елның 22 нче мартында, 19 сәгатьтә, ВКП(б) шәһәр комитетының Партия мәгарифе йортында лекция була. Тема: «Производствода электр энергиясенә экономия ясауның резервлары». Лектор—СССР фәннәр академиясенең өлкән фәнни сотрудниги иптәш Светлов. Билетларны шәһәр райкомнарыннан һәм Партия мәгарифе йортыннан алырга.

— Фронтта татар телендә чыга торган газеталардан берсенә татарча яхшы яза белә торган машинистка кирәк. Матбугат йортының 4 нче катындагы 69 нчы бүлмәгә мөрәҗәгать итәргә.

**Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.**

## ТЕАТРЛАРДА ҺӘМ КИНОЛАРДА

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген—**«Мәрьям»**.

Зур драма театры. Бүген көндез һәм кич—**«Маскарад»**.

Дәүләт циркы. Бүген өч бүлектә зур цирк тамашалары. Көндезге 12 сәгатьтә, 3 сәгатьтә һәм кич 8 сәгатьтә башлана.

Татарстан Дәүләт филармониясе. Бүген Менжинский исемендәге клубта **зур концерт**. Кич 8 сәгать 30 минутта башлана.

Яшь тамашачылар театры. Бүген 12 сәгать 30 минутта һәм көндез 4 сәгатьтә—**«Иванушка һәм гүзәл Василиса турында экият»**, кич 8 сәгатьтә—**«Кыйнадык, кыйныйбыз һәм кыйнарбыз»**.

«Электро» яңа документаль фильм — **«Сталинград»**. «Унион» көндез — **«Богдан Хмельницкий»**, кич—**«Иран»**. «Пионер» көндез—**«Вулкандагы вакыйга»**, кич—**«Минем мәхәббәтем»**. «Чатки»—**«Дубровский»**.

# СЕРГО ОРДЖОНИКИДЗЕ ТУРЫНДА ПЬЕСА

*Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры иптәш Ш. Сарымсаков белән беседа*

Галиәскәр Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, якын көннәрдә, Серго Орджоникидзе турында «Эрджикиняз» исемле яңа пьеса күрсәтә башлый. Пьесаның авторы Владимир Брагин, тәрҗемәчесе—ТАССР ның халык артисты, орденлы З. Солтанов. Пьесаны сәхнәгә РСФСР ның атказанган артисты В. Бебутов куя. Режиссер—ТАССР ның атказанган артисты Х. Сәлимҗанов. Художник—ТАССР ның атказанган сәнгать эшлеклесе, орденлы П. Сперанский. Пьесадагы баш рольне—Серго Орджоникидзе ролен—ТАССР ның атказанган артисты Камал III уйный.

Ялкынлы большевик, зур йөрәк кешесе булган Серго Орджоникидзенең образы драматург Брагин тарафыннан дөрес, тирән һәм лирик хисләр белән чагылдырылган булуы сәбәпле; бу пьеса; табигый рәвештә, театрның игътибарын үзенә тартты.

Төньяк Кавказдагы тау халкы Серго Орджоникидзены, Эрджикиняз дип атаганнар. Ингушча бу —ярлылар князе дигән сүз. Пьесаның төп темасы—халыклар бердәмлеге һәм дуслыгы. Бу теманы автор, Ленин һәм Сталин тарафыннан Көньяк Россиянең Гадәттән Тыш Комиссары итеп билгеләнгән Серго Орджоникидзе темасы белән бик нык бәйләгән.

Серго Орджоникидзе Владикавказ шәһәрендә Терек халыклары съездына җитәкчелек итә. 1918 нче елның августы. Явыз дошман һөҗүм итеп килә. Күп көннәр дәвам иткән урам сугышларында Серго, делегатлар, эшчеләр һәм кызыл армеецлар искиткеч батырлык белән катнашалар. Съездның эше өзелә, шәһәрне дошман басып ала. Серго тауларга китә. Анда аның тау халкына мөрәҗәгать итеп:

— Дошман тар-мар ителергә тиеш! Шәһәребезне яңадан кайтарып алырбыз! Съезд шул ук шәһәрдә үзенең эшен дәвам итәр!—дигән ялкынлы тавышы куәтле яңгырый. Һәм, бу чакыру тавышына җавап буларак, барлык тау халкы явыз дошманга каршы бердәм рәвештә көрәшкә күтәрелә.

Шәһәрне дошманнан кире яулап алу кебек бу зур теманы театр һәм автор, революрлар һәм пулеметлар атуын, пушкалар канонадасын күрсәтү юлы белән түгел, бәлки Серго Орджоникидзе тарафыннан төрле халыкларга, төрле социаль катлау вәкилләренә карта булган үзенчәлекле кешелек мөнәсәбәтләренең тулы бер системасы аркылы чишәләр.

Постановщик В. Бебутов шәһәрне кайтарып алу өчен көрәшүче Орджоникидзе темасын большевик-трибун турында бөек һәм дулкынландыручан трагедия итеп чишә.

Пьесаның төп образы булган Серго Орджоникидзены сәхнәдә гәүдәләндерү—ТАССР ның атказанган артисты Камал III нең зур иҗат уңышы булып тора.

Спектакльдә театрның алдынгы көчләре — РСФСР ның атказанган артисты орденлы З. Солтанов, ТАССР халык артисты К. Шамиль, РСФСР ның атказанган артисткасы орденлы Г. Болгарская, РСФСР ның атказанган артисткасы Н. Таҗдарова, ТАССР ның атказанган артистлары С. Уразиков, Х. Сәлимҗанов, артист Сәгыйтов һ. б. катнашалар.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗалыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре—73—27, типография 36—60.

ПФ 1084 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 514